**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «12» июленнән № 35-288

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2020 елның 3 ноябрендәге 2-10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының даими комиссияләре составына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы регламенты нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының кайбер депутатларының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу һәм Яңа Чишмә муниципаль районы Советына яңа вәкилләр сайлану сәбәпле:

1.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының даими депутат комиссияләре составы турында» 2020 елның 3 ноябрендәге 2-10 номерлы карарына «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими комиссиясе составы турында» 3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районы рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Советының
2020 елның 3 ноябреннән
2-10 номерлы карарына
3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Советы түбәндәге
карарлары редакциясендә:
2022 елның 11 маендагы 21-167 номерлы;
2022 елның 3 августындагы 25-191 номерлы;
2023 елның 26 маендагы 34-274 номерлы;
2023 елның 12 июлендәге 35-288 номерлы)

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими комиссиясе составы

1. Валасеев Владимир Григорьевич - комиссия рәисе
2. Вафин Рәфис Сәлихҗан улы - рәис урынбасары
3. Белоглазова Татьяна Михайловна
4. Смурыгина Ольга Валентиновна
5. Хәкимова Нәзирә Искәндәр кызы